ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ РЕЛИГИОЗНАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ,
РОССИЯ МӨФТИЛӘР ШУРАСЫ РӘИСЕ**

## МӨФТИ ШӘЕХ
## РАВИЛ ГАЙНЕТДИННЕҢ

## ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА – КОРБАН ГАЕТЕ
## МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

Мәскәү
1444 һиҗри елның
10 зө-л-хиҗҗә көне
28 июнь 2023 ел

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

**БИСМИЛЛӘӘҺИР-РАХМӘӘНИР-РАХИИИМ —**
**Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән!**

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы, һәрнәрсәне Үз мәрхәмәте белән колачлаган галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын!

Пәйгамбәребез Мөхәммәт ﷺ гә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

*Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ —*

*Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!*

**Кадерле кардәшләрем!**

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россиянең мөфтиләр шурасы һәм үз исемемнән барыгызны да бөек бәйрәм — Гыйд әл-Әдха (Корбан гаете) белән котлыйм!

Җир йөзендәге миллионлаган йөрәкләр бүген Аллаһы Тәгаләгә эчкерсез догалар белән мөрәҗәгать итә. Бу йөрәкләр бөек Корбан бәйрәме килүе сәбәпле дулкынлану һәм Аллаһы Тәгаләне, Аның мәхлүкатларын ярату хисләрен кичереп, Раббылары ризалыгы өчен корбан чалып, безне бар кылган Затның рәхмәтенә лаек булырга омтыла.

Бу көннәрдә мөбарәк Мәккәдә булган кардәшләребез өчен дә йөрәкләребез шатлык хисе белән тула. Зө-л-хиҗҗә аеның шушы көннәрендә хаҗилар Раббыбызның чакыруына буйсынып, хаҗ гамәлләрен үтәде:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

***«Кешеләрнең Аллаһ каршында вазыйфасы Бәйткә (Кәгъбәгә) Хаҗ кылудыр, әгәр алар моны үтәр хәлдә булсалар...»***

(*«Әлү Гыймран» сүрәсе, 97 а.*).

Бу көннәрдә Мәккә-и-Мөкәррәмә шәһәренә бар дөньядан миллионлаган мөселман җыелды. Алар төрле милләттән, төрле яшьтә, төрле дәрәҗәдә. Алар төрле телләрдә сөйләшә, тән төсләре төрле, горефләре һәм тарихлары да аерыла. Әмма аларның барысын да Аллаһның дине берләштерә. Илебездәге мәчетләребездә дә Корбан бәйрәменә төрле язмышлы, төрле хәлдәге һәм дәрәҗәдәге кешеләр җыела. Әмма без һәркем өчен Бер булган Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән адәм балалары. Бу бәйләнеш һәрнәрсәдән нык, ул какшамас, шул ук вакытта, чын инану булмаганда, ул бик тиз өзелергә дә мөмкин. Аллаһы Раббыбыз Изге Коръәндә корбан чалу рәвешендәге гыйбадәт төренең асылын билгеләгән:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا
وَلَكِن يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنكُمْ

**«Корбанга чалынган хайваннарның ите дә, каны да Аллаһка ирешәчәк түгел, Аңа фәкать сезнең тәкъвалыгыгыз гына барып ирешә»**

(*«Әл-Хаҗҗ» сүрәсе, 37 а.*).

Корбан бәйрәменә тагын нинди кыйммәтләр һәм мәгънәләр салынган соң? Бу көндә без Ибраһим һәм аның улы Исмәгыйль турындагы тарихны искә ала алабыз. Искә төшерик: Ибраһим пәйгамбәргә төшендә, сынау буларак, яраткан улын корбанга китерергә боерыла. Исмәгыйль әлеге боерыкны буйсынучанлык белән кабул итә һәм әтисенә мөрәҗәгать итә:

يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِن شَاء اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«И минем атам, үзең кушылган нәрсәне эшлә. Мине син, Аллаһ теләсә, түзүчеләрдән итеп табарсың», — диде»**

(*«Әс-саффат» сүрәсе, 102 а.*).

Әлеге гаҗәеп хәлне искә төшереп, үз-үзебезгә сораулар бирү зарур: бу сынауны мин ата-ана яки бала буларак нинди хисләр белән кабул итәр идем икән? Бала булсам, Аллаһының әмерен лаеклы рәвештә үти һәм әти-әниемнең карарын шундый ук буйсынучанлык белән кабул итә алыр идемме икән? Тынычлык саклап, үпкә, ярсу, ачу хисләренә бирешмичә һәм ризасызлык күрсәтмичә кала алыр идемме? Бу сорауларга җаваплар иманыбызның дәрәҗәсен билгеләргә ярдәм итәчәк. Ата белән улга бу сынауны лаеклы рәвештә узарга нәрсә ярдәм иткән соң? Иман, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәллек мөэмин-мөселманнарга берләшергә һәм Раббыларының ризалыгына ирешергә ярдәм итә.

Ике пәйгамбәрнең бу тарихы ничек тәмамлана? Ибраһим пәйгамбәр улын янга яткырып, аны корбан итәргә ниятләгәндә, ул түбәндәге сүзләрне ишетә:

يَا إِبْرَاهِيمُ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«И Ибраһим! Син төшеңне раска чыгардың. Игелек кылучыларга Без шулай әҗерен бирәбез»**

(*«Әс-саффат» сүрәсе, 104–105 а.*).

Аллаһы Тәгалә улы урынына хайванны корбан итәргә кушып, Ибраһимны туктаткан. Бу хәл кешелек өчен гыйбрәт булып тора, иманлы бәндәләр авырлыкларга һәм сынауларга әзер булырга; күндәмлек һәм сабырлык күрсәтүчеләргә, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә Үз рәхмәтен ирештерәчәгенә ышанырга тиеш. Ибраһим һәм Исмәгыйль пәйгамбәрләр узган сынауны искә төшереп, без түбәндәге сабакны да үзләштерергә тиеш: үлем һәм гомер бары тик Аллаһтан гына, ә асыл гыйбадәт ул — сәламәтлегебезне, мөлкәтебезне һәм вакытыбызны җәмгыять файдасына фида кылудан гыйбарәт. Аллаһы Тәгалә тагын бер тапкыр ассызыклый: кеше тормышының чын асылы, миссиясе, яшәү мәгънәсе башка кешеләр — туганнар, якыннар, тирә-юньдәге барча

кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә
ачыла. Бу аралашуда авырлыклар
һәм сынаулар котылгысыз, әмма Бер
Аллаһның арканына тотынсак, Аллаһка ышану
йөрәкләребезне пакъләргә булышса, авырлыкны
җиңеп була.

Кадерле дин кардәшләрем! Корбан бәйрәме өч көн дәвам итәчәк
һәм аның күркәм горефләренең берсе — һәр фарыз намаздан соң
Аллаһы Тәгаләгә мактау (*тәкбир*) ирештерү. Шулай ук бәйрәм көннәре
туганнар һәм күршеләр белән мөнәсәбәтләрне ныгытыр, мохтаҗларга, ятимнәргә,
зәгыйфьләргә игътибар итәр өчен менә дигән мөмкинлек. Иң мөһиме, бу көннәрдә
кылынган игелекле гамәлләребез киләчәктә дә даими гадәткә әверелсен иде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт ﷺ:

أَيَّامُ التَشْرِيقِ أَيَّامُ أَكْلٍ وَشُرْبٍ وَذِكْرٍ للَّه تَعَالَى

***«Тәшрикъ көннәре — ашау-эчү һәм Аллаһы Тәгаләне мактау вакыты», — дигән***

(*Мөслим «Сахих»ы*).

Бөек бәйрәмнең бу мөбарәк көннәрендә без Аллаһы Тәгаләдән кардәшләребезнең Хаҗын, корбаннарыбызны, игелекле гамәлләребезне кабул итүен һәм йөрәкләребезне үзара ярату, шәфкатьлелек һәм миһербанлык хисләре белән тулыландырып, шулай ук Ватаныбызга һәм бар кешелек дөньясына тынычлык һәм иминлек бирүен сорыйбыз!

Йөрәкләребез тәкъвалыкта һәм иманда ныгысын иде! Без гаиләләребездәге исәнлек һәм бәрәкәт, авыруларга шифасын һәм дәвасын, ярлылар белән мохтаҗларга туклык һәм муллык сорап, Раббыбызга дога кылабыз! Тагын бер тапкыр сезне бөек бәйрәм белән котлыйм! Гыйд әл-Әдха мөбарәк булсын!

*Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!*

*Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!*

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин***

*Россия Федерациясе мөселманнары*
*Диния нәзарәте рәисе*